| СОВЕТ КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 елның 16 октябре** Күгәй авылы **№ 131**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының « Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы ставкалары, тәртибе һәм түләү сроклары турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 174 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2020 елның 12 ноябрендәге 12 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының « Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон, Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының « Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы ставкалары, тәртибе һәм түләү сроклары турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 174 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карарына (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 2020 елның 12 ноябрендәге 12 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак-коммуналь комплексының торак фондына һәм (яисә) торак инфраструктурасы объектларына карамый торган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата 0,3 %;»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны 2023 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

Күгәй авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе Ф. Х. Хисаметдинова